Республика Татарстан

СОВЕТ КАВЗИЯКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ул. Советская,д.66в,с.Кавзияково,423360
Телефон:(85559 ) 4-47-16

Татарстан Республикасы

САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КӘҮҖИЯКАВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Совет урамы, 66в йорт,
Кәүҗиякавылы, 423360
Телефон: :(85559) 4 – 47-16

ОКПО 4313026 ОГРН 1021601313690 ИНН/КПП 1636001347/163601001

# КАРАР

**25.01.2016 ел** **Кәүҗияк авылы** **№ 6**

Референдум үткәрү инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 12.06.2002 ел, № 67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 22, 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 20 ст. 1 п., Кәүҗияк авыл җирлеге Уставының 11,12 ст., Сарман муниципаль районы Кәүҗияк авыл җирлеге Советы карар итә:

1. Бу мәсьәлә буенча җирле референдум үткәрүне башлап җибәрергә:

"Сез 2016 елда Кәүҗияк авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган һәр кешедән 200 сум күләмендә үзара салым кертүгә, I төркем инвалидларыннан, көндезге бүлек студентларыннан тыш , түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән килешәсезме?:

- җирлекнең торак пунктлары чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү ;

- җирлек территориясендә физик культура һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар булдыру, җирлекнең рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын үткәрүне оештыру;;

- җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру(урамнарны яктырту, территорияне яшелләндерүне дә кертеп);

- көнкүреш калдыкларын һәм чүп-чар җыюны һәм чыгаруны оештыру;

- ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту .

«ӘЙЕ ЮК» .

2. Әлеге карар мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерелергә тиеш.

Кәүҗияк Башлыгы
авыл җирлеге башлыгы Ф.Н. Әхмәтгәрәев